ГЛАВА АБСАЛЯМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.2,
с.Абсалямово, 423957

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр урамы, 2 йорт,
Әбсәләм авылы, 423957

Тел.:(85593) 4-26-79, факс:4-26-79, e-mail: Absal.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№3

КАРАР
“14” март 2024 ел

*2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы, 2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 4 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында*

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Уставының 22 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 25 мартында 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм торак пункты, Совет урамы, 50Г санлы йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында 2023 елның 22 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы, 2023 елның 22 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 4 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

1. «2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы, 2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 4 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктындагы Пушкин, Тукай урамнары буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү));

2) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында Совет урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (чокырларны ремонтлау));

3) Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (каралганча, юлларны кардан чистарту (ГСМ, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4) Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзекләндерү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү));

5) Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, коймалар урнаштыру, (корыган агачларны, куакларны кисү, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 12 мартындагы “2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы, 2023 елның 22 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 4 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында»гы 2 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4.Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Әбсәләм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карар аның игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева